КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 сентябрь г.Казань № 879

Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы, «Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәре эшләве тәртибе турында» 2019 елның 17 октябрендәге 1333 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре учреждениеләре исемлеген билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасының күзәтү һәм лаборатория тикшерүе челтәре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 18 апрель, 206 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының күзәтү һәм лаборатория тикшерүе челтәре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 18 апрель, 206 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының күзәтү һәм лаборатория тикшерүе челтәре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2008 ел, 28 июль, 542 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының күзәтү һәм лаборатория тикшерүе челтәре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 ел, 18 апрель, 206 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының күзәтү һәм лаборатория тикшерүе челтәре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2012 ел, 16 ноябрь, 1003 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 сентябрь, 879 нчы
карары белән расланды

Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм
аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы
территориаль ярдәмче челтәре турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмә гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәрен (алга таба – республика территориаль ярдәмче челтәре) оештыру һәм аларның эшләү тәртибен билгели.

1.2. Республика территориаль ярдәмче челтәре Татарстан Республикасы территориясендә хәрби низаглар булганда яки бу низаглар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда барлыкка килә торган радиацион, химик һәм биологик характердагы куркынычлардан Татарстан Республикасы халкын, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау максатларында төзелә.

1.3. Республика территориаль ярдәмче челтәре гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең бер өлеше булып тора һәм Татарстан Республикасы территориясендә радиацион, химик һәм биологик хәлләрне күзәтү һәм тикшерүдә тоту функцияләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының гамәлдәге махсуслаштырылган учреждениеләре, бүлекчәләре һәм хезмәтләре җыелмасын тәшкил итә. Республика территориаль ярдәмче челтәренә керүче учреждениеләр составы бу Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада китерелә.

1.4. Республика территориаль ярдәмче челтәре эшчәнлеген координацияләү һәм республика территориаль ярдәмче челтәре белән методик җитәкчелек итү Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.5. Республика территориаль ярдәмче челтәре эшчәнлеге Россия Федерациясе Президенты тарафыннан Россия Федерациясенең гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау планын гамәлгә кертеп башлана.

1.6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе:

учреждениеләр эшчәнлеге белән турыдан-туры җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

ел саен, 1 ноябрьгә, шәхси состав белән туплану, приборлар һәм җайланмалар белән җиһазландыру, шәхси составны шәхси саклану чаралары белән тәэмин итү һәм учреждениеләрнең функцияләре турында Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына мәгълүмат кертә. Учреждениеләр исемлегенә үзгәрешләр кертелгәндә мәгълүмат 10 көн эчендә тапшырыла;

чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда учреждениеләрнең эшчәнлегенә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүне күздә тота.

## 2. Республика территориаль ярдәмче челтәренең төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Республика территориаль ярдәмче челтәренең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

табигый мохит, табигый һәм табигый-антропоген объектлар (алга таба – әйләнә-тирә мохит) компонентларының, азык-төлекнең, хайваннар һәм үсемлекләр чыгышындагы чималларның радиоактив пычрануы, химик һәм биологик зарарлануы барлыкка килү куркынычларын күзәтү, үз вакытында ачыклау, йогышлы авыруларны (шул исәптән кеше һәм хайваннар өчен уртак булганнарын) тудыручыларны, кешенең, хайваннарның йогышлы авыруларын һәм үсемлекләрнең зарарлы һәм аеруча куркыныч организмнар белән зарарлануын китереп чыгара торган патоген биологик агентларны индикацияләү, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә мөмкин булган куркынычлыклар барлыкка килү турында мәгълүматлар кертү;

радиоактив пычрануга, химик һәм биологик зарарлануга дучар булган Татарстан Республикасы районнарын (территорияләрен) ачыклау, билгеләү һәм тамгалау өчен радиацион, химик һәм биологик разведка оештыру һәм үткәрү.

2.2. Республика территориаль ярдәмче челтәренең төп функцияләре түбәндәгеләр була:

Татарстан Республикасы территориясендә радиацион, химик һәм биологик хәл торышын күзәтү һәм аңа лаборатория тикшерүе үткәрү;

әйләнә-тирә мохиттә кешенең, хайваннарның йогышлы авыруларын китереп чыгара торган патоген биологик агентлар, үсемлекчелек объектларында һәм авыл хуҗалыгы җирләре һәм аларның төрләре территорияләрендә зарарлы һәм аеруча куркыныч зарарлы организмнар булуны билгеләү;

радиоактив матдәләр белән пычрануны, агулый торган матдәләр, аварияле химик куркыныч матдәләр һәм биологик чаралар белән зарарлануны билгеләү буенча тикшерүләр үткәрү өчен пробалар алу һәм аларны махсус учреждениеләргә илтеп бирү;

хәрби низаглар булганда яки бу низаглар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булганда барлыкка килә торган

радиацион, химик һәм биологик характердагы куркынычлар шартларында республика территориаль ярдәмче челтәре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча тәкъдимнәр эшләү.

## 3. Учреждениеләрнең эшчәнлеге һәм радиация, химик һәм биологик характердагы куркынычлар турында мәгълүмат тапшыру тәртибе

3.1. Учреждениеләрне әзерлеккә китерү тиешле планнар буенча гамәлгә ашырыла.

3.2. Учреждениеләрнең үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә әзерлеге аларның гамәлгә куючылары булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан тәэмин ителә һәм гражданнар оборонасы буенча укулар, күнекмәләр ясау һәм тикшерүләр үткәрү барышында тикшерелә.

3.3. Учреждениеләр җитәкчеләрен укытуны оештыру Россия Федерациясе законнары нигезендә гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының белем бирү учреждениеләрендә үткәрелә.

Учреждениеләр белгечләрен укытуны оештыру Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле органнарында һәм оешмаларда Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4. Радиацион, химик һәм биологик характердагы мөмкин булган куркынычлар турындагы, шулай ук аларны локальләштерү буенча күрелә торган чаралар турындагы мәгълүмат, куркынычны ачыклаганнан соң бер сәгатьтән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләр тарафыннан тапшырыла:

учреждениеләр тарафыннан – Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле башкарма органнарына һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан – Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратына һәм Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган нәтиҗәләрне бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан – гражданнар оборонасы өлкәсендә бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына.

3.5. Республика территориаль ярдәмче челтәренең эше һәм торышы турындагы хисаплар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе аша Татарстан

Республикасы халкын һәм территорияләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау торышы турындагы доклад һәм Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы торышы турындагы доклад өчен материаллар составында тапшырыла.

3.6. Республика территориаль ярдәмче челтәренең үзара хезмәттәшлеге һәм эшчәнлеген координацияләү Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы органнарның техник чараларын кулланып башкарыла.

## 4. Республика территориаль ярдәмче челтәре эшчәнлеген финанслау һәм матди-техник яктан тәэмин итү

Республика территориаль ярдәмче челтәре эшчәнлеген финанслау һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәре турындагы нигезләмәгә кушымта

Гражданнар оборонасын һәм халыкны саклауны күзәтү һәм аларга лаборатория тикшерүе челтәренең Татарстан Республикасы территориаль ярдәмче челтәренә керүче учреждениеләр составы

1. «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методик үзәге» дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесенең радиоактив пычрануга һәм химик зарарлануга дучар булган районнарны ачыклау һәм билгеләү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыручы Химик-радиометрик лабораториясе.

2. «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының Эзләү-коткару хезмәте» дәүләт казна учреждениесенең һавада төрле химик куркыныч матдәләрне һәм гамма-нурланышны ачыклау һәм билгеләү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыручы Радиация һәм химик мониторинг буенча мобиль комплексы.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы кешенең йогышлы авыруларына лаборатория диагностикасын үткәрүне, лаборатория диагностикасы нәтиҗәләре турында мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм тапшыруны гамәлгә ашыручы медицина учреждениеләре.

4. Атмосфера һавасының химик пычраткыч күрсәткечләр буенча торышын өзлексез тикшерүдә тотуны һәм, детектирлау блокларын кулланып, стационар өзлексез режимда атмосфера һавасының гамма-фонын билгеләү өлешендә радиация торышын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы, үзенең тиешле җаваплылык зоналары чикләрендә гамәлдәге күзәтү челтәре лабораторияләрен һәм лаборатория тикшерүен көчәйтү функцияләре яки кирәк булу кысаларында Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының махсуслаштырылган аналитик контроль инспекцияләре

5. Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең хайваннардан, хайван үләксәләреннән биологик (патологик) материалга, шулай ук дәүләт ветеринария хезмәте контролендә тотылырга тиешле продукция пробаларына лаборатория тикшеренүләрен гамәлгә ашыручы дәүләт ветеринария берләшмәләре.